КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 341

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының һәлакәтләр медицинасы хезмәте турында» 2014 ел, 7 июнь, 382 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының һәлакәтләр медицинасы хезмәте турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының һәлакәтләр медицинасы хезмәте турында» 2014 ел, 7 июнь, 382 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының һәлакәтләр медицинасы хезмәте турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Хезмәт үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы федераль законнарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бөтенроссия һәлакәтләр медицинасы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 26 августындагы 734 номерлы карары белән расланган Бөтенроссия һәлакәтләр медицинасы хезмәте турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 декабрь, 480 нче карары нигезендә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү

һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карарларына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.»;

5 пунктта:

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Оборона министрлыгы Үзәк хәрби округының Татарстан Республикасында урнашкан медицина бүлекчәләре»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Горький тимер юлы Казан бүлеге – «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан елга пассажирлар агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте»;

9 пунктның искәрмәсендә:

беренче абзацта «даруханә учреждениеләрен» сүзләрен «аптека оешмаларын» сүзләренә алмаштырырга, «Республика кан салу станциясе» сүзләрен «Республика кан үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «РКХ ДАССУның» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин